**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Элмәле авылында гражданнар җыены**

# КАРАРЫ

**6 нче декабрь 2021 ел Иске Элмәле №1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы “Иске Чүпрәле авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Иске Элмәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 октябрендәге 59/3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә, 2021 елның 6 декабрендә тавыш бирү йомгаклары турында, 2021 елның 6 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 314 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-161, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның 51,27 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 161 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның 100% ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде, бу 0 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2021 елның 6 декабрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының « Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Элмәле авылында гражданнар җыенын 2021 елның 6 декабрендә уздырылган, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Иске Элмәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Иске Элмәледә урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;

- Колхоз, Культура, Комсомол, Космонавтлар, Пролетар, Яңа, Заречная, Иске Элмәле урамнары буенча юл-урам челтәрен ремонтлау;

- Иске Элмәледә зиратларны тоту;

- Иске Элмәледә карт агачларны кисү;

3. 2022 елда Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Иске Элмәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә.

- Иске Элмәледә урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;

- Колхоз, Культура, Комсомол, Космонавтлар, Пролетар, Яңа, Заречная, Иске Элмәле урамнары буенча юл-урам челтәрен ремонтлау;

- Иске Элмәледә зиратларны тоту;

- Иске Элмәледә карт агачларны кисү.

4. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә кирәк: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Элмәле авылы, Үзәк урам, 23 нче йорт, Иске Элмәле башлангыч мәктәбе бинасында , Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы,**

**Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы урынбасары,**

**халык җыенында рәислек итүче: Р.Д.Низамов**